СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Куркачи, ул. Клубная, 34

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ_КАЗАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык авылы, Клуб урамы, 4

Тел./факс 8(8436570-700, e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
21 сентября 2020 г. № 1

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан муниципаль берәмлек Башлыгын сайлау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Уставының 35 статьясының 1 өлешендәге 9 пункты, 44 статьясының 2 өлеше нигезендә һәм хисап комиссиясенең 2020 елның 21 сентябрендәге 2 нче номерлы беркетмәсе нигезендә, Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгын сайлау буенча яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга һәм Закирова Гөлнара Равил кызын, 5 нче Иске-Казан бер мандатлы сайлау округы депутатын, Иске-Казан авыл җирлеге Башлыгы һәм Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге Советы рәисе итеп сайларга.
2. Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советы Башлыгы вазыйфасына керешү көне итеп аны Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан сайлау көнен санарга.
3. 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Җирле үзидарә турында” ТР законының 26 статьясының 1 өлеше һәм Иске-Казан авыл җирлеге Уставының 43 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Закирова Гөлнара Равил кызын Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләргә.
4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Рәислек итүче Э.Р. Шагиева